ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 480

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 9 » октябрь 2015 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 17.12.2014, № 201 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2015 елның 29 июнендәге "Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында" № 176-ФЗ Федераль закон нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 17.12.2014, № 201 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (ТР Юстминистрлыгында 2015 елның 02 июнендә № 2741 белән теркәлде) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.8. пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктчаларын өстәргә:

"7) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

8) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә".;

- дүртенче абзацтагы 1.11 пунктының 2 пунктчасында "7.23.1 статьясының 2 өлеше белән" сүзләрен төшереп калдырырга;

- 2.1.1 пунктының унынчы абзацында "2.1 таблицада" сүзләрен "1 таблицада" сүзләренә алмаштырырга;

- 2.1 таблицадагы "2.1" нумерациясен "1" нумерациясе белән алмаштырырга;

- 3 кисәкнең беренче абзацында "3.1 таблицада" сүзләрен "2 таблицада" сүзләренә алмаштырырга;

- 3.1 таблицадагы "3.1" нумерациясен "2" нумерациясенә алмаштырырга;

- 4 кисәкнең беренче абзацында "4.2 таблицада" сүзләрен "3 таблицада" сүзләренә алмаштырырга;

- 4.2 таблицада “4.2” нумерациясен “3” нумерациясенә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 2.4.3. пунктын өстәргә:

“2.4.3. Шушы Регламентның 2.4.2 пунктының 1, 3, 5 пункт өлешләрендә каралган нигезләрдә, шулай ук лицензиат тарафыннан лицензия таләпләре бозылу очраклары турында дәүләт торак күзәтчелеге органнарына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр, гаризалар, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар керү сәбәпле планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә һәм лицензиатка планнан тыш тикшерү турында алдан хәбәр итмичә үткәрелә”.;

- 5.1.7 пунктының алтынчы абзацында “7.23.1 статьясының 2 өлеше белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

- 5.1.7 пунктның унсигезенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

“Тикшерелә торган зат электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә риза булганда, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта тикшерелә торган затка күрсәтелгән документны алганлыкны дәлилли торган ысул белән җибәрелгән шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендәге акт кулга алынган булып санала”.;

- 5.2.4 пунктның җиденче абзацында “контрольлек буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмый торган” сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “, лицензиатка имзалатып тапшырыла һәм (яки) кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәрелә яисә күрсәтелгән документны алганлыкны дәлилли торган ысул белән шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә (тикшерелә торган затның электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта). Шул ук вакытта тапшыру турында белдерүнамә һәм (яки) кулга алу турында башка төрле дәлил ТР ДТИ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә”.

2. Шушы боерык белән ТР ДТИ башлыгы урынбасарларын, бүлекләрдәге башлыкларны һәм ТР ДТИ хезмәткәрләрен имзалатып таныштырырга;

3. Хокукый идарәгә шушы боерыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлүен гамәлгә ашырырга;

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык С.А. Крайнов.

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

ТР ДТИ башлыгы урынбасары Ф.М. Низамов

Юридик бүлек башлыгы А.А. Хәмидуллин